КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 апрель г.Казань № 297

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2016 ел, 9 август, 549 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2016 ел, 9 август, 549 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче, 2017 ел, 14 июль, 495 нче, 2018 ел, 12 апрель, 234 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, 1 һәм 2 пунктларда «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

беренче абзацта «2018 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2019 елның 31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның икенче абзацында «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2018 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыруга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә, 1.1 пунктта, 1.5 пунктының өченче, 2.2 пунктның дүртенче, 2.7 пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларында «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2018 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибендә (алга таба – Тәртип):

исемендә, 1.1 пунктта «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктның беренче абзацында «2017 ел өчен» сүзләрен «2018 ел өчен» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктта «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Субсидия алучы хезмәткәрнең санатория-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә кую турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә субсидия акчасы булганда, субсидия хезмәткәргә юллама бирү яки субсидия кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә хезмәткәрне санатория-курорт дәвалануына юллама алу өчен исәпкә  кую турында карар кабул ителгән хезмәткәргә юллама бирү турында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе белән (почта, телефон, СМС-хәбәр, электрон почта буенча) кабул ителгән карар турында хәбәр итә яки аңа хәбәр ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә, әмма санатория-курорт дәвалавы вакыты башланырга җиде эш көненнән дә соңга калмыйча 770/у номерлы форма буенча санатория-курорт оешмасына юллама алу өчен белешмә (гамәлдә булу вакыты чыккан очракта) яңарту кирәклеге турында хәбәр итә.

Субсидия алучы хезмәткәр тарафыннан 770/у номерлы форма буенча санатория-курорт оешмасына юллама алу өчен яңартылган белешмә тапшырылган көннән соң өч эш көне эчендә хезмәткәргә санатория-курорт дәвалавына юллама бирү яки аны бүлеп бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе белән (почта, телефон, СМС-хәбәр, электрон почта буенча) кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Хезмәткәргә санатория-курорт дәвалануына юллама бирүдән баш тарту өчен нигез булып хезмәткәр тарафыннан билгеләнгән вакытка 770/у формасы буенча шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен яңартылган белешмә бирмәү тора.

Субсидия алучы субсидия акчасы беткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә хезмәткәргә санатория-курорт дәвалануына юллама бирүдән баш тарту

турында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе белән (почта, телефон, СМС-хәбәр, электрон почта буенча) кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Хезмәткәргә санатория-курорт дәвалануына юллама бирүдән баш тарту өчен нигез булып субсидия чараларының җитәрлек булмавы (бетүе) тора.»;

3.1 пунктның беренче һәм икенче абзацларында «2018 елда» сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга;

1 – 3 нче кушымталарның нумерация исемнәрендә «2018 елда»сүзләрен «2019 елда» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин